ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/18

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

2009 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ санлы Федераль законга, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/20 санлы Карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хакында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 9 бүлекне өстәргә

«9 бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм булдырмау

36. Мәнфәгатьләр каршылыгы – ул Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынуы нәтиҗәсендә вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин булган хәл, андый хәл булганда, Идарә хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм ул эшләгән Идарәнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Идарәнең милкенә

һәм (яисә) абруена зыян салучы каршылыклыр туа яисә туарга мөмкин.

37. Идарә хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы яки йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык – ул Идарә хезмәткәре тарафыннан, хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә, үзе яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки милек характерындагы хезмәтләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге.

38. Идарә башлыгы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш.

39. Идарә хезмәткәре Идарә башлыгына вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш. Идарә башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәдә бирелүче мәгълүматлар исемлеге, мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе Идарә башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Зарипова Равилә Гыйлметдин кызына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча инспекциясендә «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә кертелүче үзгәрешләрне дәүләти теркәү буенча вәкаләтләр бирергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев